**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОУТЯМЫШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район, с.Старый Утямыш, ул.Мусы Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

**№150** **26.12.2024 ел**

КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль
районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2020 елның 7 февралендәге №107 карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 7 февралендәге №107 карарына (Советның 14.06.2019 №117, 30.09.2021 №42; 23.08.2024 № 115 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

- 2 абзацның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашканнары, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата».
- 3 абзацның 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.С.Мингулов